Сабира Сталберг

# Филип көймәдә



aybagar

## Сабира Сталберг

# Филип көймәдә

**Фазилә Насретдин тәрҗемәсе**
**Мария Виитасало рәсемнәре**

1 җиңел тел

aybagar

Хельсинки 2022

**Җиңел тел дәрәҗәләре**
**Дәрәҗә 1: Иң җиңел**
Дәрәҗә 2: Җиңелрәк
Дәрәҗә 3: Җиңел

Tatar, Cyrillic script
1. басма / edition

Швед телендә / Original:
Sabira Ståhlberg: *Filip på båten*
Тәрҗемә: Фазилә Насретдин
Translation: Fazile Nasretdin
Рәсемнәр / Illustrations: Maria Viitasalo

Эш төркеме: Альбина Самархан,
Камәр Яфай Ногманов, Дәрия Самалетдин,
Адилә Самалетдин, Нәргис Самалетдин

Мөхәррир: Лилия Дәүләт

© Сабира Сталберг, 2022
© Фазилә Насретдин, тәрҗемә, 2022
© Мария Виитасало, рәсемнәр, 2022

Айбагар ▸ aybagar.eu
Хельсинки / Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-77-5 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-78-2 (е-китап, PDF)

# Бүлем 1

Минем исемем Филип.
Бүген минем туган көнем.
Мин торт яратам.
Әнием бер зур торт пешерде.
Аның өсте күпертелгән каймак
һәм бакча җиләкләре
белән бизәлгән.

Торт өстендә кечкенә шәмнәр.
Аларны миңа тиздән кабызырга ярый.
Кабызгач, аларны өреп сүндерәм.
Өргәндә үземә теләк теләргә ярый.

Мин... телиммм.
Юк, әйтмим!
Алдан әйтергә ярамый бит.

Бүген минем зур бәйрәм көнем.
Бөтен нәсел кунакка чакырылган.
Барысы да өстәл артында
тезелеп утырганнар,
сөйләшеп торалар.

Әби белән бабай диванда утыралар.
Әти кунакларга каһвә кайната.

– Филип, кузиннарың белән
сөйләш, – әни әйтә.
Минем кузиннарым бишәү.
Бары тик кызлар.
Алар мине кызыксындырмый.
Нәрсә әйтим соң?

Алар атлар яраталар.
Атлар турында гына сөйләшәләр.
Алардан ат исе дә килә.
Уф, мин атлардан җирәнәм.
Минемчә, иң җирәнгеч ис – ат исе.
Кузиннарым белән сөйләшергә теләмим.

Мин әбәй белән сөйләшергә телим.
– Әбәй тиздән килер.
Поезды соңга калган, – әти әйтә.

Мин әбәйне яратам.
Ул мине аңлый.
Әбәй беркайчан
да ачуланмый.
Әмма кайда тора икән?
Ишек кыңгыравы шалтырый.
Әбәй килә!

– Әйдәгез, әле торт
ашыйбыз, – әни чакыра.

– Филип, тортның
шәмнәрен кабыз, – әти әйтә.
Шырпы тартмасын
алып киләм дә,
шәмнәрне кабызам.
– Ой, нинди матур шәмнәр! –
әбәй әйтә.
– Өреп сүндер!
Нинди дә булса теләк телә!



# Бүлем 2

Тирән генә сулыш алам,
үпкәмне һава белән тутырам да,
шәмнәргә өрәм.
Өф!
Шәмнәр барысы да берьюлы сүнә,
– Браво, – дип кардәшләр
кычкырып җибәрәләр дә,
кул чабалар.

Әни тортны кисә.
Беренче кисәген миңа бирә.
– Филип, туган көнең
котлы булсын, – әти әйтә.
– Ну, Филип, нәрсә теләр идең? –
әби сорый.
– Ат? – Динә кузиным тәкъдим итә.

Барысы да көләләр. Битем кызара.
– Әйтеп карасам ярыймы? – әни сорый.
– Уен. Компьютер уены!
– Юк, – җавап бирәм.
– Минем җитәрлек күп
уеннарым бар инде.
– Әйт инде, Филип, –
Бибинур апа кычкырып җибәрә.

– Болай безгә торт эләкми!
– Эт баласы, – әйтеп куям.
– Мин эт телим.
– Ничек алай инде, Филип, –
әни борчылып әйтә.

– Син беләсең бит, минем
аллергиям бар, – әти әйтә.
– Без эт ала алмыйбыз.
– Әмма мин эт телим, –
үзсүзләнеп әйтәм.

Әти башын чайкый.
– Алай булмый инде, Филип.
Сиңа аңларга кирәк.
Минем якынымда этләр булса,
хәлем начарая, – әти әйтә.

– Филип, ишетәсеңме, – әбәй әйтә.
– Сәяхәткә чыксак.
Яратыр идеңме?
– Сәяхәткә? Кая? –
дип аптырап калам.

– Син дә мин икәү.
Көймә белән сәяхәткә чыксак, –
әбәй җавап бирә.
Дөрес ишеттемме икән?

– Чыннан дамы?
Көймә белән? –
кычкырып җибәрәм.
– Чыннан да, – әбәй әйтә,
– иртәгә узгач юлга чыгабыз.
– Ураа, – кычкырып җибәрәм.
– Әни! Әти!
Мин көймә белән китәм!

Әбәйне кочаклыйм.
– Син дөньяның иң яхшы әбәе, –
дип әйтәм.

Әбәй көлә.
– Мин яшел чәй һәм
бер зур гына кисәк
торт теләр идем, – әйтә.

# Бүлем 3

Мин әле әбәй белән көймәдә.
Дөресен әйткәндә, бу вапур.
Вапур көймәдән зуррак.

Алай булса да, көймә дияләр.
Нигә икән шулай?
Анысын чынлап та белмим.

Көймә дөнья кадәрле зур.
Коридорлары бик озын, күпкатлы.
Катлары палуба яки дек дип атал.
Һәрьякта халык.
Бер-берләренә тавышлап эндәшәләр.
Ары-бире коридорларда йөренәләр.
Берәүләре зур сумкалар күтәргән.
Һәрберсе үз каютасын эзли.

‒ Көймәдәге бүлмәләр каюта
дип атала, ‒ әбәй әйтә.

Без дә үз каютабызны эзлибез.
Аны табу җиңел эш түгел.
Дивардагы номерларга карап барабыз.
Бер коридорга керәбез дә,
сулга борылабыз.

Аннары уңга әйләнәбез,
ләкин каютабыз анда түгел.
‒ Бу көймә ‒ бер лабиринт, ‒
әбәй пуфылдап әйтә.
‒ Каютабызны табарбызмы икән,
ни уйлыйсың?
Тагын да уңга борылабыз.

‒ Ниһаять! ‒ әбәй тынычланып әйтә.
‒ Тегендә.
Каюта номеры 7258.
Ишекнең биген ачып
каютабызга керәбез.
Ул байтак кечкенә.
Каютада ике ятак
һәм юыну бүлмәсе.

‒ Мин өстәге ятакта
йокларга телим, ‒ әйтәм.
‒ Ярар, мин бик риза, ‒
әбәй әйтә.

Чанталарыбызны идәнгә куябыз.
‒ Әйдә, югары деккә барыйк, ‒
әбәй әйтә.
‒ Анда көймәнең лиманнан
чыкканын күрә алабыз.
Бинокләңне онытма.

Бинокльне әти миңа туган көн
бүләге итеп биргән иде.
Ул яңа һәм бик ачык күрсәтә.
Дүрбүнне, бинокльне, савытыннан
чыгарам да, муеныма асам.

Лифт белән унынчы деккә менәбез.

Аннан тышка, көймәнең
ян-ягындагы деккә чыгабыз.
Анда халык шыгрым тулы.

Һәрберсе көймәнең лиманнан
чыкканын күрергә тели.
Дүрбүнем белән диңгезгә карыйм.

Ой! Диңгез тып-тын.

# Бүлем 4

Диңгез гадәттә яшел
яки зәңгәр төстә була.
Ләкин бүген алтын кебек ялтырый.
– Кояш түбәндә, – әбәй аңлата.
– Ул күк йөзен сарыга буйый да,
күкнең төсе диңгездә чагыла.
– Матур, – әйтәм.
– Әле китәбез, –
әбәй кычкырып ала.
– Дүрбүнеңне тот.

Көймәнең моторлары
даңгыр-доңгыр итә.
Бөтен көймә селкенә.
Аннары әкрен генә
шуып лиманнан аерыла.
Дүрбүн белән карыйм.
Бер атауда маяк күрәм.
Маяк ак, уты кабына да сүнә.

– Әбәй, бак, маяк, – кычкырып җибәрәм.
– Бир, карыйм.
Дүрбүнне әбәйгә сузам.
Ул да маякка карый.
– Ой нинди матур, – әбәй сокланып әйтә.

– Тегендә нәрсә?
Җилкәнле көймәләр.
Сигез... тугыз... юк,
унике җилкәнле көймә, – әбәй саный.
– Кая? Бир, мин дә карыйм, –
кызыгып сорыйм.

Әбәй дүрбүнне миңа суза.
– Ундүрт җилкәнле көймә, –
санап куям.
– Чыннан дамы? – әбәй сорый.
– Алай булса, мин дөрес санамадым.
Без җилкәнле көймәләргә
озак карап торабыз.

Искәрмәстән әбәй әйтә:
– Филип, өшисеңме?
Диңгездән салкын җил өрә.
– Юк, – җавап бирәм.
– Өшемим.
Йон күлмәгем яхшы җылыта.

Йон күлмәкне әни миңа туган көн
бүләге итеп биргән иде.
Ул аны үзе бәйләгән.
Йон күлмәк зур һәм калын.
Ак белән зәңгәр сызыклары бар.
Чыннан да җылы.

Әмма әбәй өши.
Өстендә юка күлмәк кенә.
– Мин йон күлмәгемне киеп киләм, –
әбәй әйтә.
– Минем белән барасыңмы
яки теләбрәк монда көтәсеңме?
– Мин сине монда көтәм, – җавап бирәм.
– Җилкәнле көймәләр карарга телим.

– Мин шуннан ук кайтам, – әбәй әйтә.
– Дүрбүнеңне диңгезгә төшермә.
– Тиз генә кайт, –
әйтәм.
– Ачыга башладым.
– Мин кайткач ашарбыз, – әбәй әйтә.
– Пицца ничек булыр?
– Бик тә тәмле булыр, – җавап бирәм.

Әбәй каютага китә дә,
мин җилкәнле
көймәләр карарга калам.
Алар тын гына диңгездә шуып йөзәләр.
Зур аккошлар кебек.
Шундый матурлар!

# Бүлем 5

Кинәт аркам артында
әллә нинди тавыш ишетелә.
Нәрсәдер тырнап тора.
Тирә-ягыма карыйм.
Дек буп-буш.
Мин дектә япа-ялгыз.

Халык юк булган.
Ресторханнарда утыралардыр
яки кибетләрдә әйберләр
сатып алалардыр.

Тагын тырный.
Нәрсә икән?
Тирә-ягымны җентекләп карап чыгам.
Тыңлыйм, ләкин тып-тын.

Әле тагын тырный.
Тавыш зур сандыктан килә.
Дивар янында бер яшел сандык тора.

Сандык янына барам.
Өстендә нидер язылган.
– Коткару жилетлары, укып чыгарам.
Тукта! Жилетлар шыгырдамый бит.

Нәрсә икән?
Кемдер яки нәрсәдер сандык эчендә.
Анда аны ябып куйганнар.
Капкачын ачарга тырышам,
ләкин сандык бикләнгән.
Пәкем кайда икән?
Кесәләремдә казынам,
ләкин пәкемне тапмыйм.

Әй инде! Пәке бишмәтемнең кесәсендә,
билгеле, ә бишмәтем каютада.
Тагын тырный.
Сандык артына күз салам.
Әле аны күрәм.
Кечкенә эт. Аклы-көрәнле эт баласы.
Колаклары озын, күзләре табак тикле.
Шыңшый да, мине күрә.

Исем-акылым китеп этне күзәтәм.
‒ Сәлам сиңа, ‒ әйтәм.
Эт качарга тырыша.
Миннән курка кебек.
‒ Монда ничек эләктең? ‒ сорыйм.
Ул сандыкны алгы тәпиләре
белән тырный.
‒ Сандык артында син нишләп ятасың?
‒ сүземне давам итәм.
‒ Тилердеңме?

# Бүлем 6

Эт кузгалмый да.
Мине дикъкать белән тыңлый.
Зур, кара күзләре белән миңа карап тора.
Миңа калса, эт байтак күңелсез кебек.
– Мескен кечерүк, – әйтәм.
– Берүзең генәме?

Тирә-ягыма карыйм.
Беркем күренми.
– Хуҗаң кайда? – сорыйм.
– Качтыңмы яки хуҗаңны да,
әннәңне дә югалттыңмы?
Алар сине эзлиләрдер.

Хуҗаңны табарга кирәк.
Әмма ничек?
Бераз уйлыйм.
Әлбәттә!
Бик җиңел эш.
Һәр этнең муенында муенчак бар.
Анда адресы да бар.

Ләкин этне ничек чыгарыйм?
– Әйдә акыллым, чык, – дип әйдим.
– Акыллым!

Сандык өстенә тезләнәм дә,
кулымны сузам.
– Чык, – дип чакырам.
– Хуҗаңны эзлибез.

Эт, әлбәттә, теләми.
Эчкәрәк кача да, урынында
утырган килеш чиный.

– Чык аннан, – әйтәм.
– Курыкма. Сиңа булышырга телим.

Эт алай булса да кузгалмый.
– Мин куркыныч түгел, – аңлатам.
– Мин акыллы, бик акыллы.
Кесәмдә карамель дә бар.

Бер карамель чыгарам да,
эткә күрсәтәм.
– Менә сиңа бераз татлы, – әйтәм.

Эт утырган урынында
карамельне иснәп ала.
Йөрәкне өзеп чиный башлый.

– Әйдә инде, – мин
сабырсызланып кычкырам.
– Юкса сине күтәреп чыгарам.

Сандык өстенә корсагым
белән ятам да,
кулымны сузам.
– Әле сиңа тыңлаучан булырга кирәк, –
әйтәм.
– Миңа, Филипкә кил.

Эткә тотынып карыйм.
Ул йомшак һәм җылы.
Сабыр гына утыра да көтә.
Мин аны күтәреп алам.

– Син бик авыр, –
сулыш алып әйтәм.
– Сине көчкә күтәрә алам.

Ул вау дип шат өрә дә,
кулымны ялый.

# Бүлем 7

Этне кочаклап сандык өстенә утырам.
– Син нинди тәти, – диям.
Этне кочаклыйм.
– Мин дә мондый
эт теләр идем.
Бик сөйкемле.

Әмма эт калтырый.
Куркадыр, бәлки өши дә.
– Өшисеңме? – сорыйм.
– Мескен кечкенә вау-вау!
Этне кочаклыйм.
Ул калтыранып борынын йон
күлмәгемнең эченә тыга.
– Бик инде озын колакларың, –
эткә әйтәм.

Этнең колаклары чыннан да озын.
Алгы тәпиләрен һәм
башын бергә санасаң,
колаклары озынрак.
Беркайчан да мондый
озын колаклы эт күргәнем юк иде.
Дөресен әйткәндә, мондый
эт тә әүвәл күргәнем юк иде.

Кечкенә, кыска аяклары,
кечкенә койрыгы.
Йөзе бөрешкән.
Күзләре куе кара-көрән,
кара дип әйтеп була.
Токымы ни икән,
уйланып торам?
Озын колаклы, йөзе бөрешкән.

Аклы-көрәнле туны...
Әле белдем!
Ул бассет.
Бассетларны рәсемнәрдә күргәнем бар.
Дөресен әйткәндә,
эт искиткеч ямьсез,
ләкин бер үк вакытта сөйкемле дә.
Тагын кочаклыйм.

Ул борынын миңа таба бора да,
битемне ялый.
Бөтенләй юешләнәм.
– Ой, телең бик кытыршы, –
көлеп җибәрәм.
– Вау, – дип өрә.

Уйнап кына мине тешләргә тырыша.
Тешләре әлегә кечкенә,
сөт тешләре.

Этләрнең яше турында
укыганым бар.
Бу эт баласы берничә айлык.

– Исемең ничек? – сорыйм.
Эт койрыгын селкетә.
Кайгылы күзләре
белән миңа карый.

Әлбәттә, җавап
бирә алмый.
Аннары муенчак
исемә төшә.
Муен бавы!
Этнең муенын капшыйм.

Муенчагы юк.



# Бүлем 8

Сәер.
Этләрнең муенчагы булырга тиеш.
Анда адрес һәм телефон номеры була.
– Синең муенчагың кайда? – сорыйм.

Эт койрыгын селкетә генә.
Кулымны тешләргә тырыша.
Озак уйланып торам.
Әле нишлим?

Этнең исеме дә юк,
адресы дә юк.
Иясе көймәдә булырга тиеш.
Әмма кайда?

Мин эткә карыйм.
Ул миңа бага.
Мине ярата,
мин дә аны бик яратам.

– Синең исемең Бассе булсын, –
карар кылам.
– Бик кызык исем.
Миңа калса, сиңа килешә дә.
Бассе борынын култыгыма тыга.

Тагын калтырана.
Ул өши.
Мин дә өшим.
Диңгездән боз кебек салкын җил исә.
Бассене кочагыма күтәрәм.

‒ Әйдә, эчкә керәбез.
Эчтә җылырак, ‒ әйтәм.
Эчтә якты һәм җылы.

Бассены кочагымда тотам.
Борыныма аш исе бәрелә.
Авызыма сулар килә.

Ой, бик ачыкканмын икән!

Кинәттән әбәй исемә төшә.
Ул соң кайда?
Каютабыз еракта түгел бит.
Әбәйгә монда булырга
кирәк иде инде.

Мин бер эскәмиягә утырам.
Бассены кочагымда тотам.
Ул башта идәнгә сикерергә тырыша.
Аннары култыгыма керә.
Йокысы килә дә, авызын ача,
күзләрен йома.

Артык калтырамый.
Мин утырып әбәйне көтәм.
Көткәндә Бассеның
колак артын һәм
аркасын кашып торам.

Ул тыныч кына сулыш ала да,
кочагымда бик тиз йокыга китә.
Колагына тотынып карыйм.
Колагы кыймылдап китә,
әмма Бассе уянмый.

Ул тирән йокыда.

# Бүлем 9

Телефоным шалтырый.
Әбәй шалтырата.
– Һей Филип, хәлең ничек? – әбәй сорый.
– Яхшы, – әйтәм.
– Син кайда?

– Каютада, – әбәй әйтә.
– Килгәндә бер танышыма очрадым.
Байтак озак сөйләштек.
Хәлләр ничек?
Барып ашыйкмы әле?

– Әлбәттә, – әйтәм.
– Әбәй, беләсеңме нәрсә?
Мин бер...

Хы! Элемтә өзелде.
Әбәйгә шалтыратырга тырышам,
әмма ул җавап бирми.

Тагын тырышам. Җавап юк.
Өченче кат шалтыратам,
әмма әле дә җавап юк.

Хәзер нишлим?

Каютабызны табарга кирәк.
Әбәй анда мине көтә.
Ә Бассе белән нишлим?
Аны ялгыз калдыра алмыйм.
Йөгереп тагын тышка чыгар да,
диңгезгә төшәр.
Яки кем дә булса аны таптап китәр.
Ул бит әлдә нәни эт баласы
гына, саклана белми.

Бассены үзем белән алып барырга кирәк.
Әбәй иясен табарга
миңа ярдәм итәр.
Бассены күтәреп кулыма алам.
Ул уяна да исни, авызын ача.
Аннары чинап ала.
Уятканны яратмый.

– Гафу! Әбәйне барып алырга кирәк, –
әйтәм.
– Аны тапкач,
барып ашарбыз.
Мин бик каты ачыктым,
син дә ачыккансың.

Бассе койрыгын селкетә дә,
тәпиләрен җилкәмә куя.
Башта мырылдый.

Аннары битемне ялый да,
колагыма өрә.
– Алай каты ярамый, – көләм.
– Колагымны авырттырасың бит!

Үземне бик бәхетле тоям.
Шул ук вакытта
үземне бәхетсез дә хис итәм.
Бассе бик кыска вакытка
гына минем этем.

Тиздән иясен очратабыз да,
этне биреп җибәрергә кирәк була.
Хуҗасы беркайчан да
табылмасын иде,
бөтен йөрәгемнән телим.
Аннары Бассе миндә
калыр иде дә,
мәңгегә минеке булыр иде.

# Бүлем 10

Бассе тирә-ягын күзәтеп тора.
Тәпиләре белән җилкәмә таянган.
Ни булганнарны барысын да
күрергә тели.
Арада узып баручыларга өрә.
Мин дә тирә-ягымны күзәтәм.

Лифтлар кайда?
Лифт белән каютага
баралыр идем,
ләкин лифтлар кайда, хәтерләмим.

Алдымда бер баскыч кына.
Баскычтан әкрен генә аска таба төшәм.
Аскы катта дек номер тугыз.
Миңа җиденче деккә барырга кирәк.
Ул әлдә ике кат астарак.

Каршыбызга бер төркем
кызлар киләләр.
Янымда туктыйлар да,
шунда җыелып калалар.

Миңа һич тә исләре китми,
Бассега сокланганнар.

‒ Бик татлы! ‒ берсе кычкырып җибәрә.
‒ Бик сөйкемле кечкенә вау-вау, ‒
икенчесе әйтә.
‒ Инде матур маэмай, ‒
кызлар барысы да
бертавыштан кычкырып җибәрә.

Бассеның колак артын һәм дә
муен астын кашып алалар.
Аркасын да кашыйлар.

Бассе өрә дә, койрыгын селкетә.
Ул кашыганны ярата.

‒ Бу синекеме? ‒
кызлардан берсе сорый.
Җавап бирмим.
Кызарынам да колакларым кайнарлана.

‒ Син нинди бәхетле, ‒ кыз
көнләгәндәй әйтә дә, сулап ала.
Ул Бассены бик озак кашып тора.

‒ Мин эт баласы теләр идем,
әнием аны карый алмам дип уйлый.
Кыз тагын сулап ала.
Аннары кызлар йөгереп
үз юлларына китәләр.

Баскыч басмасына утырам.
– Минем этем булса идең, –
Бассега әйтәм.
– Бик теләр идем.
Чыннан да теләр идем.

Бассены каты кочаклыйм да,
ул чиный.
Дүрбүнне һәм дүрбүн
бавын кимерә башлый.

– Тукта, – көләм.
– Бавын чәйнәмә, өзелер.
– Вау, вау, – Бассе өрә.

Көлгән кебек була.
– Әле безгә әбәйне
эзләргә кирәк, – әйтәм.

# Бүлем 11

Аягүрә торам да,
Бассены күтәреп җиденче деккә төшәм.
Безнең каютабыз биредә булырга тиеш.
Каютада әбәй мине көтә.
Әмма каюта кайда?

Бер коридорга керәм.
Уң якта ишекләр күп, сул якта да бар.
Ишекләрдәге номерлар
һәммәсе җиде белән башлана.
Берсе дә җиде һәм ике белән башланмый.
Бассе башын җилкәмә куя.
Мине ул тынычландыра.
Икенче коридорга әйләнеп керәм.
Анда да җиде белән ике юк.

Бер зәңгәр униформалы апа
каршыма килә дә:
– Сиңа ярдәм итә аламмы?
Кемне булса эзлисеңме, – сораша.
– Мин каюта номер 7258
не эзлим, – җавап бирәм.
– Киләсе коридорга бар да, уңга борыл.
Аннары туры алга бар да,
сулга әйлән, – апа әйтә.

– Рәхмәт, – әйтәм.
– Байтак авыр,
әмма каютаны табармын инде.

Яндагы коридорга керәм дә,
уңга борылам.
Аннары туры алга таба барам.
Әмма яндагы коридорда
сулга илтә торган юл юк.

Уңга әйләнәм. Бәлки апа уңга диде?
Ләкин анда каюталар юк,
ялгыз бер шкаф кына.
Ялгыш аңлаганмын.
Теге апа белән очрашкан урынга
кире кайтырга телим.
Ләкин әле инде аны тапмыйм,
сорарга да кем дә юк.
Беркем дә коридорда күренми.
Һәрьяк тып-тын.

Әбәйгә шалтыратырга тырышам,
әмма ул җавап бирми.
Бер диварга сөяләм.
Эт таптым да, әбәйне югалттым.
Коридорны таптым да,
каютаны югалттым.
Әле нишлим?

# Бүлем 12

Бассе борынымны ялый.
Ул мине юатырга тели.
– Син акыллы, – әйтәм.
– Әбәйне ничек табарбыз?

Тәмам шул вакытта тавыш
яңгыраткычыннан белгертәләр:
– Камил, инфога кил.
Кәримә сине көтә.
Камил, сине көтәбез.
Инфога кил, –
яңгыраткычтан кабатлыйлар.

Башымда бер фикер туа.
Мин инфобюрога бара алам бит!
Аннан әбәйгә кычкырта алам.
Әбәй, әлбәттә, каютабызда
яңгыраткыч тавышын ишетә.

Димәк, миңа коридорлар буйлап
каютабызны эзләргә кирәкми.
Инфобюроны гына табарга кирәк.
Анда ашыгам.
Бассены кочагымда тотып,
коридор буйлап йөгерәм.

Кинәт мин лифтлар янында.
Анда харита, карта, бар.
Хаританы укыйм.
Әһә!
Инфо дүртенче дектә.
Лифтка керәм.
Лифт дүртенче деккә илтә.
Шатланам.

Тиздән әбәйне табам инде!
Инфобюрога йөгерәм.
Анда өстәл артында бер кыз утыра.
Ул телефоннан сөйләшә.
Сөйләвен бетерә,
ләкин телефон тагын шалтырый.

Өстәл янына барам.
Өстәл янында бер ир кеше басып тора.
Ачулыга охшый.
Кыз миңа дикъкать итми.
Әле икенче телефон шалтырый.

Кыз ике телефонда да
бер үк вакытта сөйләшә.
Әле телефоннарның берсен яба.
Аннары ир белән сөйләшеп ала.
Ир кычкыра, кулларын селкетә.
Кыз икенче телефонын да яба.

– Гафу итегез, – кызга әйтәм.
– Мин…
– Үз рәтеңне көтәргә кирәк, –
ир ачуланып кычкыра.
– Әмма… – әйтәм.
– Әбәемне югалттым.

– Бер минут, – кыз әйтә.
– Тегендә эскәмиягә
барып утыр да көт.

Өстәл якынындагы
эскәмияне күрсәтә.
Утырам да көтәм.

Кайчан булса да миңа
вакыты булыр микән?

# Бүлем 13

Әбәйгә тагын шалтыратып карыйм,
әмма телефон эшләми.
Батареясы бетә дә,
телефон үлә. Һаман да шулай!

Көтәм дә көтәм.
Телефонны тагын ачам, әле эшли.
Бераз көче калган.
Әбәйгә шалтыратып карыйм,
ләкин телефон сүнә.

Өстәл артындагы кызның миңа вакыты юк.
Ир кычкыра да орыша.
Кызга ярдәм сорарга туры килә.

Ике униформалы ир кеше инфо
өстәле янына килә.
Орышучы ир белән сөйләшәләр,
ләкин ул улавын дәвам итә.
Әле миңа уйларга кирәк.
Бассе дүрбүн бавын чәйни.
Дүрбүнне дә кимерергә тырыша,
әмма ул артык каты.
Аннары күлмәгемдәге төймәне
кимерә башлый.

Бассенең селәгәе бик ага да,
күлмәгем юешләнә.
Уйлыйм да уйлыйм.

Әбәйне эзләргә кирәк,
әмма каютаны таба алмыйм.
Инфобюроның да миңа
бернинди дә ярдәме юк,
телефон да эшләми.

Әбәй мине эзли.
Бәлки өстәге деккә барыр?
Мин анда көтәргә булдым бит.
Димәк, ул деккә
кире кайтырга кирәк.

– Ишетәсеңме Бассе, – әйтәм.
– Тукта, күлмәгемне
чәйнәмә, ярармы акыллым.
Яхшы эт, юк, тешләмә!
Әбәй тышкы дектә,
мине эзли.

Бассе башын кырын
куя да, койрыгын селкетә.
– Алайса әйдә, – дип әйтәм. –
Әбәй өстәге дектә.
Аны беләм, шик тә юк.

# Бүлем 14

Лифтларга таба барам,
әмма әллә кая адашам.
Лифтларны тапмыйм.
Кинәт мин бер киң коридорда.
Анда кибетләр бар һәм дә кеше күп.

Беренче кибет хушбуйлар сата.
Кибеттән көчле хуш исләр аңкып тора.
Төчкерәм, Бассе да төчкерә.
Мин аңардан көләм.
Төчкергәндә аның колаклары җилферди.
Борынын да бөрештерә.
Бик көлкегә охшый.

Шунда безне ике апа узып китә.
– Тьфу! – дип берсе кычкырып җибәрә.
– Эт. Фу!
Көймәгә көчек китерергә ярыймы?
Тыярга кирәк иде.
– Мескен эт, – икенчесе әйтә.
– Көймәдә торырга яратмыйдыр да ул.

– Этеңне өйдә калдырырга иде, –
беренчесе әйтә.
– Аны көймәгә алып килмәскә иде.

Этләр сәяхәт итәргә яратмыйлар.
Эт балалары бигрәк тә нәзек.
– Бу минеке түгел, – җавап бирәм.
– Мин аны таптым, – дип аңлатам.
– Әйе, әйе, – апа әйтә.
– Ни әйткәнемне онытма.
Киләчәк мәртәбә этне өйдә калдыр.
– Ярый, – дип ямьле генә
баш иеп әйтәм.

Апалар юлларын дәвам итәләр.
Мин икенче якка таба китәм.
Анда чанталар һәм
шарфлар сата торган кибет.
Аның янында ризык кибете.
Дөнья кадәрле ачыктым.

Бассега да ашамлык алырга
кирәк булыр иде.
Кесәләремне капшыйм да,
бераз вак акча табам.
Ни булса татлы алырга җитәр инде.

Эт ризыгы кибеттә бар микән?
Кибеткә керәм дигәндә,
униформалы ир мине туктата.
– Кибеткә этләр кертәргә ярамый, –
кисәтеп куя.

– Бассе эт баласы гына әлдә, – әйтәм.
– Нәни эт.
Аны миңа кочакта тотарга кирәк.
Тотмасам, качып китә, – аңлатам.

– Кибеткә этләр кертәргә ярамый, –
сакчы ачуланып кабатлый.
Туп-туры алдыма килеп баса.
Сөйкемсезгә охшый.
Әйләнәм дә кире борылып китәм.



# Бүлем 15

Елыйсым килә.
Күз яшемне сөртеп алам.
Нигә барысы да Бассега бәйләнә?
Этләр яратмыйлар микән?

Бассе беркайчан да беркемне дә
авырттырырга теләми.
Бераз тешли генә,
чөнки теш уртлары кычыта.
Әле аның сөт тешләре төшәргә тора да,
аннары ит тешләре чыга.
Шуңа курә ул куркыныч түгел.

Бер кибетнең диварында
белдерү тактасы. Белдерү тактасында
кызыл түгәрәк эчендә эт рәсеме.
Анда да этләр кертәргә ярамый.

Коридорның икенче очында баскыч.
Ниһаять. Баскычтан менә башлыйм.
Бассе кулымда бик авыр тоела.
Хәзер ял итәргә туры килә.
Баскыч басмасына утырам.
Биредә кеше дә юк,
беркем мине борчымый.

Телефонны кесәдән чыгарам.
Әле тагын эшли.
Аңлап җитеп булмый.
Кайчак эшли, аннары тагын эшләми.
Әбәйгә шалтыратып карыйм,
ләкин ул җавап бирми.
Телефон шалтырый да шалтырый.
Тагын шалтыратам.
Җавап юк.
Аннары телефон сүнә.

Бассе тынычсыз кыймылдана.
Борыла да, әйләнә,
койрыгын селкетә.
Зур күзләре белән миңа карый.

Кинәт кулымнан котыла.
Сикереп идәнгә төшә дә,
янымда утырып кала.
Утырган җиреннән
торганда келәм өстендә
юеш эз кала.

Бассе өрә дә качып китә.
Тәмам шул вакытта әбәй шалтырата.

– Алло, Филип, син кайда? –
әбәй телефонда кычкыра.

# Бүлем 16

– Бассе кача! – әбәйгә кычкырам.
Телефон сүнә.

Телефонны тиз-тиз кесәмә салам да,
Бассе артыннан атылам.
Ул каты йөгерә.
Колаклары канатлар кебек кагыла.
Хәзер очып китә!

Әмма Бассе очмый.
Бигрәк тиз йөгерә.
Кыска тәпиләре идәндә
тыпыр-тыпыр итә.
Койрыгы туп-туры үрә тора.
Мин көчемнән килгән кадәр
тиз йөгерәм, әмма аны тота алмыйм.

Ой! Дүрбүн бавы ычкына.
Бассе аны тешләп өзгән.
Дүрбүн кулымнан төшә.
Бәхетемә чак кына тотып өлгерәм.

Дүрбүнне кулымда тотам да йөгерәм.
Бассе бер коридорга әйләнеп керә.
Аннары икенчегә борыла.

Уңга атыла, аннары сулга.
– Көт, – дип пуфылдап әйтәм.
– Тукта! Бассе!

Бассеның миңа исе дә китми.
Биек баскычтан шат кына
сикерә-сикерә төшә.
Ярдәм! Егылып төшәр!
Баскыч беркайчан да бетми.
Юк, әле бетте!

Бассе бер озын коридорга
йөгереп керә.
Аннары тагын баскычтан
аска таба сикереп бара.
Басмалары ничә икән, белмим.
Мин йөгерәм генә.

Бассе әле икенче коридорга
борылып керә.
Мин артыннан атылам.

Ниһаять! Коридор бетә.
Бассе ерагракка йөгерә алмый.
Шөкер, коридорда бер генә ишек,
ул да бикләнгән.

– Әле тотылдың, – Бассега кычкырам.

# Бүлем 17

Кинәт Бассе туктый.
Кире йөгереп китәргә тырыша,
ләкин мин аны тотам,
каты гына тотып торам.

Ул кочагымда каушана.
Йөгерергә генә тели.
Әмма мин йөгергәнен теләмим.

– Ахмак эт.
Кая барасың? – сорыйм.
– Качып китмәсәң, әйбәтрәк.
Аны син белергә тиеш.

Шунда әбәй исемә төшә.
Дүрбүнне кулымнан
сакланып кына куям.
Бер кулым белән телефонны
кесәмнән чыгарам.
Икенче кулым белән Бассены тотам.

Телефон эшләми.
Бассе тагын качарга тырыша.
Ул кабырсый да өрә.
Кулымны тешләргә керешә.

Аның тешләре бик үткен.
– Ай! Тынычлан, –
сабырсызланып кычкырам.

Алдыбыздагы ишекне ачарга тырышам,
әмма ул бикләнгән.

Без кайда икән?
Моннан ничек чыга алабыз?

Ишектә автолар деге дип язылган.
Без кайдадыр көймәнең
иң астагы катында.
Бөтенләй ялгыш килгәнбез.

Кире борылам.
Тышка чыгарга
бер генә юл бар.
Баскыч.
Өскә таба гына менеп була.

Бассены бер култыгыма,
дүрбүнне икенчесенә кыстырам.

Баскычтан менә башлыйм,
әмма Бассе менәргә теләми.
Ул өрә дә,
кулымнан качарга ертына.

– Өскә менәргә
кирәк, – әйтәм.
– Аска бара алмыйбыз.
Анда аста су гына.
Өстә әбәй һәм ризык бар, – аңлатам.

Бассе мырылдый да өрә.
Мин аны кочаклыйм.
– Тиздән ни булса ашарсың, –
ышандырам.
– Бик тә тиз.
Моннан чыгарга юл
табарга кирәк.



# Бүлем 18

Баскычтан менәм. Баскыч биек.
Бассе бик авыр.
Менгән саен авырая бара.
Дүрбүн дә авыр.

Бассены кулымнан җибәрә алмыйм,
ул аннары тагын кача.
Җилкәмә күтәрәм дә,
ул сикереп төшәргә тырыша.

Миңа аны икекуллап тотарга кирәк.
Дүрбүнне дә беркая да куя алмыйм.
Ох!
Дүрбүнне кулымда тотам да,
Бассены кочаклыйм.
Тир бора, арый башлыйм.

Ниһаять, баскыч бетә.
Озын гына коридорга киләбез.
Туп-туры алга таба барам.
Коридор кинәт бетә.
Уң якка таба бер юл ачыла.
Һәрьякта ишекләр,
әмма беркем дә юк.
Бик каты арыдым, туктарга кирәк.

Идәнгә утырам.
Көймәнең коридорлары чиксез күп.
Әбәй дөрес әйтә. Көймә бер лабиринт.
Бер ишеккә шакылдатыйммы икән?
Бәлки берәү миңа ярдәм итәр.
Тыңлап торам. Беркайдан да
бер тавыш та ишетелми.

Сәгатемә карыйм. Кичке аш вакыты.
Барысы да әле ресторанда
кичке ашларын ашыйлар.
Эчем авырта кебек,
чөнки бик ачыктым.
Аш турында уйласам, тагын да
күбрәк ачыгам.

Торам да юлымны дәвам итәм.
Бассены кочагымда күтәреп барам.
Күп-күп басмалар менәм,
ничә-ничә коридор үтәм.

Хәзер инде һич тә көчем калмады,
әмма моннан чыгу юлын табарга кирәк.
Миңа әбәйне яки
инфобюроны табарга кирәк.
Яки дә безгә ярдәм итә ала
торган берәүне.
Кемне генә?

# Бүлем 19

Бассе рәхәтсез.
Мин аны кочагымда бераз
тирбәтәм дә, ул тынычлана.
Әкрен атлап юлымны дәвам итәм.

Бассе тәпиләрен җилкәмә куя.
Башын тәпиләре өстенә сала да,
колагымны иснәп тора.
Кинәт аш исен сизәм.

Бассе башын күтәрә.
Без бер иркен урынга килеп чыгабыз.
Шунда ресторан,
аның янында кафе.

Каты сусаганымны сизәм.
Кафеда ни булса эчәргә алып буладыр.
Анда ширбәт һәм су бар.
Кесәмнән вак акча чыгарам.

Бер стакан ширбәткә җитә.
Барып алам дигәндә,
бер яшь ир миңа таба килә.
Зур буйлы, сары чәчле.
Өстендә кара тишөрт, футболка.

Миңа сәер карый.
Бассега һәм дүрбүнгә
тагын да сәеррәк карый.
Чат каршымда туктый.

– Карак, – дип кычкырып җибәрә.



# Бүлем 20

Тәнемне салкын баса.
Ир куллары белән җилкәмнән тота да,
мине селкетә башлый.

Аннары Бассены миннән тартып
алырга тырыша. Бассе дәртләнеп өрә.
– Ай! Авырттыра, – кычкырып җибәрәм.
Котылырга тырышам.
– Этне монда бир, – ир улый.
Җилкәмнән тотып мине селкетә.
– Тукта! Җибәр! – кычкырам.

Бассены тотып торам да,
китәргә тырышам.
Ләкин ир миннән тизрәк.
Беләгемнән тота да тарта.
Бик каты кулымны бөгә,
дүрбүн кулымнан ычкынып идәнгә төшә.
– Этне монда бир! – ир акыра.
– Дүрбүн! – кычкырам.
– Яңа дүрбүнемне ваттың!
Ир беләгемнән тотып каты гына тарта.
– Ярдәм итегез, – кычкырам.
Кафедагы халык безне күзәтеп тора.
Башта беркем дә кузгалмый.

Аннары берәүләре тора да,
безнең яныбызга килә.
Иргә мине җибәрергә кушалар.

Ләкин ир мине каты тота.
Йөзе һәм муены кып-кызыл.
– Бу малай кыз дустымның
этен урлаган, – дип каты кычкыра.
– Мин аны урламадым, – каршы куям.
Елый башлыйм.
– Ярамас бала, – ир кычкыра.

Тагын да Бассены миннән алырга тырыша.
Бассе өрә дә, ирнең кулын тешли.
– Афәрин эт, – пышылдыйм.
– Ай! – ир кычырып җибәрә. – Тиле эт!

– Тынычланыгыз, – бер абый әйтә.
– Әле бу эшне тикшерәбез.
Малайны җибәр.
Абый ирнең беләгеннән каты гына тота.
Ир мине җибәрә,
әмма миңа ямьсез бага.
Авыр сулап ала.
Бассе аңа өреп тора.
Мин дүрбүнне идәннән күтәрәм.
– Аңлат әле, – абый әйтә.
– Нәрсә булды?

# Бүлем 21

– Кыз дустымның эте бар, – ир әйтә.
– Бассет баласы.
Без тышкы дектә булганда,
ул качып китте.
Без аны һәрьякта эзләп йөрдек.

– Кыз дустың кайда, – бер апа сорый.
– Ул этен эзләп йөри, – ир җавап бирә.
– Алай икән, – апа әйтә.
– Ә бу малай?

Апа яхшы кешегә охшый.
Ул минем хәлемне аңлый шикелле.
Күз яшьләремне сөртеп алам.
Бассе тынычлана.
Тәпиләрен җилкәмә куя,
колагыма чиный, битемне ялап ала.

– Этне тышкы дектә таптым, –
борын астыннан гына җавап кайтарам.
– Инфобюрога да бардым.
Миңа кемнең дә исе китмәде.
Мин әбәемне эзлим.

– Алай икән, – апа әйтә.

– Минемчә, мәсьәләне болай чишик.
Син кыз дустыңа шалтырат.
Ә син әбәеңә шалтырат.

Телефонны кесәмнән чыгарам.
Эшләсен иде инде,
дип өметләнәм.
Әйе, эшли.
Шөкер.

– Филип, ниһаять! –
әбәйнең тавышы
телефонда яңгырый.
– Син кайда соң?
– Кафе алдында,– әйтәм.
– Хәзер ук монда кил.
Эш ашыгыч.

Әбәй аңлый.
– Мин анда биш минуттан булырмын, –
дип ышандыра.
– Бар да яхшымы?
– Юк, – үксеп җавап бирәм.
– Монда кризис.
– Аны уздырабыз, –
әбәй тыныч кына җавап бирә.

# Бүлем 22

Бик озын булып тоелган
җиде минуттан егерме сигез
секунттан соң әбәй килеп җитә.
Мин аны йөгереп каршы алам.

– Бер-беребезне югалттык, –
дип кычкырып җибәрәм.
– Каютабызны эзләдек, тапмадык.
Аннары Бассе качып китте дә,
астагы катка автолар дегенә эләктек.
Дүрбүнем кулымнан
идәнгә төште.
Ватылды дип уйлыйм, – аңлатам.

– Кайгырма, – дип әбәй сүземне бүлә.
Кулъяулык бирә дә, мине кочаклый.
Шуннан ук хәлем җиңеләеп китә.
– Бассе кем? – әбәй сорый.
– Эт, – дип җавап бирәм.
– Аңладым, ләкин бу кешеләр кемнәр?
– Эт минеке, – ир кычкырып әйтә.
– Малай этне урлады.

Мин Бассены бик каты кочаклыйм.
Ул ыңрана башлый.

– Һич тә ышанмыйм, –
әбәй кырт кисеп әйтә.
– Филип урламый.
Ул мин белгән малайлардан
иң тугрылыклысы.

Шул вакытта кемдер кычкырып җибәрә.
Бер кыз яныма йөгереп килә дә,
Бассены кочагымнан тартып ала.
Мин аптырап калам.
Берни дә эшли алмыйм.
Күземне кызга гына
төбәп торам.



– Фрида, – кыз
кычкырып җибәрә.
– Ниһаять!
Син кайда идең?
Тәти карчыгым!
Мин бик кайгырдым.

Бассеның борынын үбә.
Бассе өрә.

# Бүлем 23

– Алай икән.
Этнең исеме Фрида икән, –
әбәй әйтә.
– Кем минем алтынымны тапты? –
кыз сораша да, тирә-ягына багына.
– Филип, – әбәй әйтә.
– Ул этеңне бик яхшы караган.
Малай дустың Филиптән
гафу сорарга тиеш.

– Рәхмәт, Филип акыллым, –
кыз кычкырып җибәрә.
Битемне үбә. Ике тапкыр үбә.
Битем юп-юеш була.
Җир ярылса, җир астына кереп
китәр идем дип хис итәм.

– Филип, син искиткеч!
Рәхмәт, рәхмәт, –
кыз кычкыра да, Бассены үбә.
– Ә гафу сорау? – әбәй сорый.

– Вилле, Филиптән гафу сора, –
кыз әйтә.
Ирнең исеме Вилле икән.

Аның йөзе агара.
Борчылганга охшый.

– Гафу, Филип, – дип мыгырдый.
– Гафу үтенәм.
Бик ачулы идем.
Этебез качкач, бик куркындык.
Вилле миңа кулын суза.

– Ә дүрбүн? – әбәй сорап куя.

Вилле дүрбүнне кулымнан ала.
Селкетеп карый.
Һәр ягын тикшереп ала.

– Дүрбүн ватылмаган,
бавы гына өзелгән, – дип әйтә.
– Бассе аны чәйнәп өзде, – әйтәм.
– Вау, – Бассе шат кына өреп җибәрә.

– Фрида матур эт бит! –
кыз кычкырып җибәрә.

Кыз Бассе-Фриданы үбә.
Эт тә кызның борынын ялый.

# Бүлем 24

Кафеда халык яңадан
үз урыннарына кайта.

Без – кыз, Вилле, әбәй һәм
мин генә аякта басып калабыз.
Һәм, әлбәттә, Бассе-Фрида.

Әбәй кызга җитди карый.
– Сиңа этеңне яхшырак карарга кирәк.
Филип аны тышкы дектә таптым
дип аңлатты, – әбәй әйтә.

– Тышкы дектә! –
кыз кычкырып җибәрә.
– Минем мескен кечкенә Фридам!
– Этең качарга ярата, –
мин белгертәм.
– Ул еракка, астагы автолар
дегенә кадәр йөгереп качып китте.

– Этнең муенчагы кайда? – әбәй сорый.
– Фриданың муен бавы юк.
Ул ансыз сөйкемлерәк, –
кыз җавап бирә.
Кыз этнең борынын үбә.

Әле әбәй чыннан да ачулана.
Йөзе агарып китә.

– Эт уенчык түгел, –
әбәй ачуланып әйтә.
– Моны исеңдә тот!
Кызның битләре кызара,
ләкин берни әйтми.
– Сау булыгыз, – әбәй әйтә.
– Филип, әйдә!
– Бассе, хуш, сау бул, – әйтәм.

Этнең башын кашып алам.
Бассе-Фрида койрыгын селкетә дә,
зур күзләре белән миңа карый.
Эт кайгылыга охшый.
Мин дә кайгылы.
Бик кайгылы.

Йөрәгем авыр булып китә.
Күземдә яшьләр,
ләкин керфекләремне
йомгалап аларны юк итәм.

Әбәй кулын җилкәмә куя.
Пиццериягә таба барабыз.
Дүрбүнемне кулымда
күтәреп барам.

Артта Бассе-Фриданың
өргән тавышын ишетәм.
Күптапкыр йоткалагач кына
тагын сөйләшә алам.

– Бәхетемә дүрбүнем
ватылмады, – әйтәм.
– Яңа бау алырбыз.

Әбәй көлеп җибәрә.
– Беләсеңме, Филип, –
әбәй әйтә.
– Син югала беләсең,
ләкин әлдә яхшырак
табыла беләсең.

# Бүлем 25

– Әбәй, – әйтәм.
– Бассе минем этем булса иде.
Бик теләр идем.

Әбәй җитди башын кагып:
– Әйе, мин дә шуны теләр идем, – әйтә.
– Син аны яхшы карар идең.
Теге кыз һич тә эт карый белми.
Ничек этен тыштагы дектә югалта ала?

– Бассе ачыккандыр инде, уйланып әйтәм.

– Мин дә, – әбәй әйтә.
– Туна балыклы пицца телисеңме?

– Әлбәттә, – әйтәм.
– Һәм дә сыры күп булсын!

**Филип әбәе белән көймә сәяхәтенә чыга.**



**Тышкы дектә эт баласы таба. Этнең хуҗасын эзли, ләкин аны табу җиңел эш булып чыкмый.**

**Әбәен югалта һәм тиздән үзе дә юлыннан адаша. Эт баласы да качып китә…**

1 җиңел тел

978-952-7334-77-5

ISBN 978-952-7334-77-5 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-78-2 (е-китап, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**